| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ГЛАЗОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ<br>ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ГЛАЗОВО<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

9 август 2019 ел №19

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Глазово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2015 елның 27 октябрендәге 36 номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү турында (2017 елның 30 маендагы 11номерлы, 2018 елның 14 декабрендәге 29 номерлы үзгәрешләре белән)

Россия Федерациясе Салым кодексының 391, 394нче статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Глазово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районыны «Глазово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2015 елның 27 октябрендәге 36 номерлы «Җир салымы турында» Карарына (2017 елның 30 маендагы 11 номерлы, 2018 елның 14 декабрендәге 29 номерлы үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) 3нче пункт 5нче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

б) 5.1 пунктның 2, 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документлар салым органында юк, шул исәптән салым түләүченең салым ташламасын бирү турында салым түләүченең гаризасында күрсәтелгән мәгълүмат буенча салым органы салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы белешмәләрне соратып ала.

Салым органының салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслый торган белешмәләрне тапшыру турында салым органы яисә башка зат аны алганнан соң җиде көн эчендә яки шул ук вакытта салым органына запросның үтәлмәү сәбәпләре турында хәбәр итә.»;

2. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Глазово авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советының 2015 елның 26 октябрендәге 36 номерлы “Җир салымы турында”карарына үзгәрешләр кертү турында» (2017 елның 30 маендагы 11,2018 елның 14 декабрендәге 20

номерлы үзгәрешләре белән), 2019 елның 11 июнендәге 17 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.

3. Әлеге карарны Глазово авылында урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) “Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

4. Әлеге Карар рәсми басылып чыккан көненнән соң бер ай үткәннән соң гына үз көченә керә һәм 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

«Глазово авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге Башлыгы
Совет Рәисе Н.К.Карабаева